**Игътибар: ◆ Яңа рубрика—*Гасырлар кайтавазы***

**Күптән түгел генә районыбызда җөмһүриятебезнең танылган һәм мәшһүр композиторы, халык иҗаты өстендә җаны-тәне белән бирелеп эшләүче Мәсгудә ханым Шәмсетдинова булып китте. Аның безнең районга икенче сәфәрнамәсе. Беренчесендә алган тәэсирләре, районга, аның халкына булган мәхәббәте Мәсгудә ханымны яңа очрашуларга талпындырган, канатландырган. «Искиткеч халык яши, биредә?!», — дип соклана ул балыкбистәлеләр хакында. «Гасырлар кайтавазы»,—дигән рубриканы безнең газета битләрендә шушы бөек сәнгать остасы ачып җибәрә икән, бездән бер теләк кенә өстисе кала: «Изге сәгатьтә—яңа рубрикабыз!». Ә Мәсгудә ханымга без рәхмәтлебез.**

# «РИБНА СВУБУДА. РАЗЫФА САЛЯМ»

Бөтендөнья профессиональ композиторларының мәшһүр «Варшава көзе» исемле фестивалендә кичке концерт тыңлап утырам. Янымда өлкән яшьтәге кеше килеп утырды һәм мөлаем гына немец телендә сәлам бирде. Мин аңа инглизчә, белгәнем чә, җавап бирдем. Дөньяда белгән телләрне вата — сындыра сөйләшеп киттек. Минем яңа танышым Швеция иле Дәүләт Радиокомпаниясенең музыка редакторы Фолке Рабе иде. Кыска гына очрашуларда, концерт араларында Фолке миннән Татарстан һәм татарлар турында сорашты. Чит ил халыкларының безнең татар милләте турындагы фикерләренең ялгышлыклары мине шаккатырды. Имеш, без урманда яшәүче, аттан төшмәгән, кәкре аяклы, чи ит ашаучы кыргый халык. Европада пешеп бетмәгән канлы итне—«татарча кыздырылган ит» дип атыйлар икән. 21 нче гасыр ишек какканда борын-борыннан югары мәдәниятка ия булган халкыбыз турында коточкыч ялгыш мәгълүмат ишетү, миндә рәнҗү хисе уятты. Тамчы тама-тама күл була, дигәндәй, хатлар яза-яза, чакыра-чакыра теңкәләренә тиеп беткәч, Швеция радиокомпаниясе Фолкены һәм аның ярдәмчесе Мате Аймерсонны Татарстанга командировкага җибәрде. Гүзәл Казаныбыз, музей, сәнгати биналар белән танышкач, алар авылда яшәгән татар халкы белән очрашырга дигән теләкләрен белдерделәр. Шведлар, тәрҗемәче һәм мин, ниһаять, Балык бистәсендә. Бистәдә безне хакимият вәкиле каршы алды. Без Олы Елгада нурлы йөзле татар әбиләренең курчак кебек бизәлгән йортларында булдык, клубларда концертлар тыңладык. «Масловка» совхозында уңыш нәтиҗәләре белән дә кызыксынды Швед корреспондентлары. Мин аларның профессиональ дәрәҗәләренә сокландым. Эшләрен тәмамламыйча, эшнең бөтен нечкәлеген аңламыйча ялга тукталмыйлар. Алар икесе дә музыкант. Фолке Рабе профессиональ музыка редакторы, ә Мате —халык иҗаты буенча редактор. Балык бистәсендә шведларга сюрприз әзерләгәннәр. Очрашуның иң гүзәл мизгелен соңга кичергәннәр күрәсең. Бер вакыт безнең янга машина белән төбәнәк буйлы, коңгырт күзле, чемкара чәчле, скрипка тоткан хатын-кыз алып килделәр. Күңелем олы бәхет сизенгәндәй—«Ah!» итте. Шведларның да профессиональ сизгерлеге кабынды. Безнең каршыда Илһам Шакиров бөеклегендәге талантка ия булган Габдрахман кызы Разыйфа Дәүлиева иде.

Менә скрипка кылларына смычок үрелде... менә смычок тавыш биреп җир белән күкне тоташтырырга теләгәндәй талпынды... Сихри авазлар безнең барыбызны да мәңгелек һәм мизгел дәрьясына аттылар. Аһәң ташкынында бөтерелеп тарих дулкынында тирбәләбез. Бу аһәңдә халкыбызның бәхете һәм шатлыгы, канга чумган гасырлары, хыяллары, челпәрәмә килгән дөньялары, нәфрәте һәм мәхәббәте.

Разыйфа апа уйный да, уйный скрипкада. Мин елыймын. Шведлар тын калып тыңлыйлар. Талантны аңларга тел кирәкми шул. Олы талант ул Бистәдә дә талант — Стокгольмда да талант. Өф-өф итеп тәрбияләнеп үсәргә тиеш булган моң иясе Разыйфа апа яшь чагында олы-олы тракторлар йөрткән, илаһи гүзәллекне тасвирлау өчен яратылган куллары олы көрәк тотып кочегаркада күмер ташыган. Шведлар тәрҗемәче аша Разыйфа ападан сорыйлар: «Сез нигә укымадыгыз?».

Разыйфа: «Ике абыем сугыштан әйләнеп кайтмады, өченче абыем яра газапларыннан вафат булды. Ялгыз эти-әниемне тәрбияләдем. Тормышлар да бик авыр булды ул вакытта, ай, авыр тормыш булды. Безнең күргәннәрне сөйләп күрсәтсәң—ышанмассыз».

Шведлар: «Ә сезнең авылыгызда музыка мәктәбе булгандыр бит?». Әллә юләрләрме болар дигән мәгънәле карашы белән генә миңа күз сирпеп алды скрипкачы ханым. «Ай буе иртән тордык—сезнең моңнар, кич яттык—сезнең моңнар» дип яздылар Швециядән.

Тапшыруларның берсен Разыйфа Дәүлиеваның скрипкада уйнау осталыгына багышлаганнар. Хәзер дә Фолке хатларында «Рибна Свубуда Разыфа салям» дип өстәп куя.

Быел Казан консерваториясе студентлары өчен үткәрелә торган фольклор экспедициясен Балык бистәсенә алып килдек. Разыйфа апа хәлен белергә кердем. Бу очрашуда да ул мине таң калдырды. Җырлар язган. Көен дә, сүзен дә үзе язган. Күтәреп алып район җыры итәрлек җырлар.

**Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА,**
**Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор.**

Редакциядән: Р. Дәүлиеваның Балык бистәсе турындагы җыры белән 4 биттә таныша аласыз.